| | |
|---|---|
| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>**Кама Тамагы муниципаль районының**<br>**Тәмте**<br>**авыл җирлеге**<br>**Башкарма комитеты** | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>**Камско-Устьинский муниципальный район**<br>**Исполнительный комитет**<br>**Теньковского**<br>**сельского поселения** |
| Кама Тамагы районы,<br>Тәмте авылы<br>тел. 8-(84377)- 31-1-76 | Камско-Устьинский район,<br>с. Теньки<br>тел. 8-(84377)- 31-1-76 |

# КАРАР

**2022 елның 31 гыйнвары** **№5**

**2022 елга «Татарстан Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында»Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. . Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 6964 сум 68 тиен күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен

раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, 2 нче Октябрь ур., 50 (мәдәният йорты бинасы);

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, Октябрь урамы, 88А йорт (авыл җирлеге администрациясе бинасы), шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче И.А. Зиновьев

Кама Тамагы муниципаль районының
Тәмте авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2022елның 31
гыйнварындагы 5 номерлы карарына
1 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге нда җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләрнең бәяләре

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 4173,42 |
| 3. Үлгән кешенең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 593,88 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2197,38 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Кама Тамагы муниципаль районының
Тәмте авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2022елның 31
гыйнварындагы 5 номерлы карарына
2 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге нда җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләрнең бәяләре

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 214,18 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3959,24 |
| 4. Үлгән кешенең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 593,88 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2197,38 |
| Барлыгы | 6964,68 |